СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №139 (7438) | 21 ноябрь, 1992 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Советының XII сессиясендә ирешелгән килешү нигезендә Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасының уникенче чакырылыш Югары Советының XIII сессиясен 1992 елның 30 ноябрендә Казан шәһәрендә чакырырга.

Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. МӨХӘММӘТШИН.

РАЙОН АДМИНИСТРАЦИЯСЕНДӘ

Октябрь район администрациясе «Россия» колхозы механизаторларының 1993 нче ел кыр эшләренә авыл хуҗалыгы техникасын сыйфатлы һәм үзвакытында әзерләү буенча районның барлык механизаторларына мөрәҗәгатен бик вакытлы, кирәкле дип тапты. Район хуҗалыклары җитәкчеләре, баш белгечләренә әлеге мөрәҗәгатьне урыннарда механизаторлар, ремонт бригадасы членнары белән өйрәнеп, авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлауны срогында һәм сыйфатлы оештыруны йөкләде.

Ниятләре зурдан

Норлат сугару-киптерү системаларын эксплуатацияләү идарәсе. Бу көннәрдә коллектив яңа омтылышлар, яңа ниятләр белән яши. Алар идарәне коллектив предприятие итеп үзгәртергә җыеналар. Хәзер биредә акционерлаштыру буенча беренче хәстәрлекләр күрелә, аның уңышлы хәл ителәсенә ышанычлары зур.

Идарәдә тагы бер сөенечле вакыйга булды: НУЭООС каршында анда эшләүчеләрнең промышленность һәм азык-төлек товарларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен үз кибетләре ачылды.

Сәүдә базасына — диплом

Районара сәүдә базасы. Бу атнада коллектив өчен шатлыклы вакыйга булды: республика экономик ярышында катнашып, III кварталда ирешкән уңай күрсәткечләре өчен «Иң яхшы хезмәт коллективы» дипломы тапшырылды. Аны Татпотребсоюзның азык-төлек идарәсе начальнигы А. Ф. Сотин тапшырды.

Районара сәүдә базасы директоры И. С. Сафиуллин дипломны кабул итеп, бу уңышның тулы коллектив тырышлыгы булуын ассызыклады. Бу чорда базалылар күпләп сату товар әйләнеше планын 158,5 процентка үтәделәр, табыш алу планы да уңышлы гамәлгә ашырылды. Шул ук вакытта база хезмәт күрсәтә торган районнарда ваклап сату товар әйләнешенең арттырып үтәлүенә ирешелде. Ислам Сәлихович киләчәктә дә коллективның шул максатын күздә тотып эшләргә омтылачагын белдерде. Җыелышта район администрациясе башлыгы урынбасары Р. Ф. Җамалиев катнашты.

«Россия» колхозы механизаторларының 1993 ел кыр эшләренә авыл хуҗалыгы техникасын сыйфатлы һәм үзвакытында әзерләү буенча районның барлык механизаторларына

МӨРӘҖӘГАТЕ

Агымдагы ел район игенчеләрен байтак кына уңышлары белән шатландырды. Безнең «Россия» колхозы өчен дә ул күркәм күрсәткечләре белән истә калырлык булды: колхоз кырларының һәр гектарыннан 32,1 центнер бөртекле культуралар, 205 центнер чөгендер җыеп алынды. Шуның нәтиҗәсендә хуҗалык районда беренчеләрдән булып ашлык һәм чөгендер тапшыру буенча дәүләт планнарын уңышлы гамәлгә ашырды. Югары уңыш авыл эшчәннәрен ашлык белән, үзебезне һәм тирә-күрше хуҗалыкларны да сыйфатлы орлык белән, җәмәгать малларын кышлату чорына җитәрлек күләмдә һәр шартлы терлеккә 27 центнер азык берәмлеге исәбеннән азык белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Әлбәттә, бу күрсәткечләрнең төп нигезе — авыл хуҗалыгы культураларын чәчү, карау һәм җыюда агротехник таләпләрне үтәү, җир белән эшләү — аны ашлау, эшкәртү, сыйфатлы чәчү материалларын файдалану. Шуның белән бергә, игенчеләрнең хезмәтен оештыру, булган техниканы җитештерүчән файдалану, аны һәр авыл хуҗалыгы кампаниясенә тиешле камиллектә һәм сыйфатлы әзерләүнең дә әһәмиятен гаҗәеп зурдан саныйбыз. Бер сүз белән әйткәндә, уңыш өчен көрәш ел әйләнәсенә барганда гына җирдән юмартлык көтәргә мөмкин. Без моңа елдан-ел ныграк инанабыз һәм эшебезне дә уйлабрак оештырырга тырышабыз, чөнки һәр ел игенче өчен уңыш кына түгел, тәҗрибә дә, сабак та китерә. Агымдагы урак тәмамлануга, безнең колхоз игенчеләре көзге кыр эшләренә бердәм керештеләр: тиешле күләмдә җирләр туңга сөрелде, 610 гектарда кыска срокларда уҗым чәчелде. Басуларда үткәрелергә тиешле мөһим агрочаралардан сөрү горизонтын тирәнәйтү, көзге культивация, минераль ашламалар кертүгә дә игътибар тиешенчә куелды. Үткән еллар тәҗрибәсеннән чыгып, быел колхоз киләсе ел уңышы астына басуларның һәр гектарына 200 килограмм тәэсир итүче матдә исәбеннән минераль ашламалар кертүне, гектарга 9 тонна органик сый чыгаруны максат итеп куйды. Хуҗалык 100 процент күләмендә чәчү стандартының 1 классы таләпләренә җавап бирерлек орлык туплады. Колхоз игенчеләре киләчәктә дә бөртекле культуралар орлыгы үстерү юнәлешендә эшне дәвам итәргә, киләсе елдан азык культуралары мәйданнарын тагы да киңәйтергә, 320 гектарда бөртек технологиясе буенча кукуруз игәргә планлаштыра. Бу зур күләмле эшләрне уңышлы башкарып чыгу өчен механизаторларны агротехника нигезләренә өйрәтү максатында агроукулар үткәрү, аларның классслылыгын күтәрү юнәлешендә эшләр планлаштырабыз. Кышкы агрочараларны үзвакытында үткәрү, сугаруны дөрес оештыруга да игътибар көчәйтеләчәк. Хәзер машина-трактор паркын җаваплы сезонга әзерләү буенча киң эш җәелдерелде. Колхоз карамагындагы машина-трактор паркы куәте ягыннан заманча һәм яңа техника белән коралланган диеп булмый, шуңа да бөртек һәм азык җыю комбайннары, көпчәкле һәм чылбырлы тракторлар, инвентарьлар һәм җайланмаларны берләштергән паркны эш чорына сыйфатлы итеп әзерләү өчен аерата зур көч сорала. Бәхеткә, механизаторлар һәм ремонт бригадаларының җитештерүчән хезмәте өчен уңайлыклы шартлар бар: мастерскойлар, цехларыбыз җылы, уңайлыклы, көнкүреш бүлмәләре — душы, сауналары бер дигән итеп җиһазланган.

Ремонтта катнашучы механизаторлар өчен материаль кызыксындыру чаралары да эшләнде. Алар арасында ремонтны 15 ноябрьгә тәмамлаучылар өчен икеләтә түләү, комбайннарны үзвакытында сыйфатлы көйләүчеләргә зур күләмдә акчалата премия кебек нәтиҗәле чаралар да бар. Мондый шартлар механизаторларның эшкә омтылышын бермә-бер күтәрә. Игенчеләр техника паркын тулысынча аякка бастыру, иске техниканы гамәлдән чыгармыйча, аның гомерен озайтуны төп максат итеп куялар. Хәзердән инде культиваторлар, бөртек чәчкечләре, таккычлар һәм катоклар ремонтлап бетерелде. Паркта үрнәк тәртип булдыру, тиешле срокка техниканы сыйфатлы итеп әзерләп чыгасыбызга ышанычыбыз нык һәм шуңа без район механизаторларына мөрәҗәгать итәргә булдык.

Кадерле иптәшләр!

Киләсе ел уңышы язмышы безнең тырышлыгыбызга, намуслы хезмәтебезгә турыдан-туры бәйләнгән. Шуңа да чәчү һәм туфрак эшкәртү комплексын 1993 елның мартына, тракторлар һәм сугару машиналарын 15 мартка, азык әзерләү техникасын 1993 елның 1 маена, бөртек җыю, чапкычлар, орлык чистарту һәм киптерү комплексын 15 июньгә, бәрәңге, кукуруз һәм чөгендер җыю техникасын 1 августка тулысынча әзерлек сызыгына куярга чакырып мөрәҗәгать итәбез. Бу уңайдан «Сельхозхимия», «Сельхозтехника» район берләшмәләре, НУЭООС предприятиесенең якыннан торып булышлыгына исәп тотабыз. Техниканы сыйфатлы көйләү, машина-трактор паркында үрнәк тәртип булдыру, машиналарны сак һәм нәтиҗәле файдалану уңышыбызны гарантияләүче төп факторларның мөһимнәре, шуңа да без ышанабыз: мөрәҗәгать җиргә бирелгән, ашлык язмышы белән яшәгән һәр игенче, һәр механизатор күңелендә киң яклау һәм хуплау табар.

Мөрәҗәгать «Россия» колхозы механизаторларының гомуми җыелышында тикшерелде һәм кабул ителде.

Планнар үтәлә

Норлат сөт-май заводы коллективы барлык юнәлештә дә яхшы эшләде. Мәсәлән, товар продукциясе җитештерү буенча 9 айлык план 100,4 процентка, май ясау — 102,8, коры казеин 146,8 процентка үтәлде. 9 ай эчендә 21 миллион 385 мең сумлык табыш алынды.

Шулай ук халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү 99 миллион 809 мең сум, ягъни 115,6 процент тәшкил итте. Колхоз һәм совхозлардан көн саен китерелгән сөткә анализ ясауда лаборантка Рәсимә Шәйдуллина өлгерлек күрсәтә. Цехлар арасында казеин цехы иң яхшысы дип табылды, алар продукция җитештерүдә зур тырышлык белән эшлиләр. Әлеге цех эшчесе Римма Шәйдуллина турында иптәшләре аерата әйбәт фикердә, аны цехның алдынгы эшчесе итеп күрсәтәләр. Шулай ук май ясау цехыннан Людмила Калыгина исеме дә хөрмәт белән аталды. Заводның көйле эшләвендә өлкән мастер Асия Далгатовна Камалетдинованың да оештыру сәләте зур роль уйный.

Ю. ПАВЛОВА.

КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

Соңгы вакытларда Мәскәү сырхауханәләрендә пенсионерлар ишәеп китте. Алар бирегә бер генә максат белән — берничә көн генә булса да туйганчы ашап калу өчен керәләр. Өйләрендә бу мескен картларны ачлык һәм хәерчелек көтә. Шуңа күрә алар юк чирләрен дә бар итеп сырхауханәдә озаграк ятарга тырышалар, ә кайберләре хәтта сәламәтлекләренә үз куллары белән зыян сала.

⊙

Урыс телле укучылар өчен Татарстанда тагын бер газета — «Независимость» чыга башлады. Газета үзенең максатын түбәндәгечә билгели: «Татарстан халкының бәйсез, мөстәкыйль дәүләттә яшәргә теләк белдерүенә нигезләнеп, яңа газета Татарстандагы халыкларның икътисади һәм сәяси ирекге өчен көрәш барышын киң яктыртачак». Хезмәттәшләребезгә бу изге эштә уңышлар юлдаш булсын.

⊙

Россия ваучерларына Татарстанның үз ваучерлары өстәләчәк. Беренчеләреннән аермалы буларак, аларны сатып җибәрү мөмкин булмаячак. Икенче аерымлыгы — аларның бәясе. Татарстан ваучерлары 30—40 меңнән дә ким булмас дип көтелә. Моңа өстәп фатирларны сатып алу өчен хосусыйлаштыру, чекларын бирү дә каралган. Татарстан ваучерлары киләсе елның февраль-март айларында бирелә башлый.

⊙

Казанда метро төзү буенча эшләр дәвам итә. Бу турыда шәһәрнең баш архитекторы урынбасары белдерде. Проектлаштыру эшләре тәмамланганнан соң 1995 елда метро төзү эше башланачак.

Юрист аңлатма бирә

Хезмәт законнарында яңалыклар

1992 елның 6 октябреннән «РСФСР хезмәт турындагы законнар Кодексына үзгәрешләр, өстәмәләр кертү турында» Россия Федерациясе Законы хәрәкәткә кертелде. Базар экономикасына күчкәндә күп урыннарда штат кыскартулар көтелгәндә бу газета укучыларның күбесендә кызыксыну уятуын исәпкә алып, аңа юрист аңлатмасы бирәбез.

Иң башлап шуны билгеләп узу кирәк, хезмәт турындагы законнар Кодексына (КЗоТ), кертелгән өстәмәләр шактый күп. Аларның барын газетадагы бер мәкаләдә генә гәүдәләндерү мөмкин түгел. Шуны исәпкә алып, иң мөһим һәм характерлы үзгәрешләренә генә тукталырга туры килә.

КЗоТка «контракт» төшенчәсен кертү шундый яңалыкларның берсе булып тора. Дөрес, законда контракт шартларында хокук мөнәсәбәтләре тәртипкә салынмаган әле. Ләкин хәзер КЗоТның 18 маддәсе (статьясы) нигезендә контракт кына түгел, гадәти хезмәт килешүләре дә язма рәвештә төзелә.

Приватизацияләү һәм дәүләт милкен хосусыйлаштыру башланган этапта 29 маддәдәге үзгәрешләр хезмәт коллективы интересларын яклап кертелгән. Элек предприятие хуҗасы үзгәрү эштән бушатуга китерсә, законның яңа редакциясендә бу маддәнең икенче кисәгендә милек хуҗасы үзгәргәндә, шулай ук предприятиене үзгәрткәндә (кушканда, берләштергәндә, бүлгәндә, яңача оештырганда) работникның ризалыгы белән хезмәт килешүе дәвам иттерелә. Бу очракта администрация инициативасы буенча килешүне (контрактны) работниклар штатын киметкәндә генә өзәргә мөмкин.

31 нче маддәгә кертелгән яңалык работникка билгеләнмәгән срокка төзелгән хезмәт килешүен (контрактны) язма рәвештә ике атна алдан кисәткәннән соң өзәргә хокук бирә. (Элек ул үз теләге белән ике айдан соң гына китә ала иде). Аның үз теләге буенча китү турында гаризасы эшен дәвам итә алмау белән бәйле булганда (укырга керү, пенсиягә чыгу һәм башка очраклар) администрация хезмәт килешүен (контрактны) работник сораган срокта өзә.

КЗоТның работниклар санын яки штатын кыскартканда эштә калдыруга өстенлекне хокуктан файдаланучылар категориясен билгеләүче маддәгә:

уйлап табучылар;

сроктан тыш хезмәт итүчеләр (сверхсрочниклар), запаска күчерелгән яки отставкага чыгарылган хәрби хезмәткәрләр, прапорщиклар, мичманнар, офицерлар составы, хәрби хезмәттән демобилизацияләнгәннән соң беренче хезмәт урынына урнашучылар;

Чернобыль катастрофасы нәтиҗәсендә килеп туган нурланыш кәчәю аркасында нурланыш авыруы һәм башка төр авырулар алган яисә кичергән кешеләр;

Чернобыль катастрофасы нәтиҗәләре аркасында инвалидлыкка чыгуы расланган инвалидлар;

1986—1990 елларда Чернобыль катастрофасының читләштерү зонасында авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучылар, шулай ук читләштерү зонасыннан эвакуацияләнгән, чыгару зонасыннан күчерелгәннәр;

аларга тиңләштерелгән башка кешеләр өстәлә.

Яңа редакциядә КЗоТның 35 маддәсендә администрация инициативасы буенча хезмәт килешүен (контрактны) өзү очрагында тиешле сайлаулы профсоюз органының алдан ризалыгын алу;

предприятиедә (предприятие, учреждение, оешма бетерелү очракларыннан тыш) работниклар саны яки штаты кыскартылганда;

эшченең яки хезмәткәрнең биләгән вазифасына яки башкара торган хезмәтенә квалификациясе җитешмәү яисә бу эшне башкару өчен сәламәтлеге мөмкинлек бирмәве ачыкланган очракларда;

вакытлыча хезмәткә сәләтен югалту сәбәпле өзлексез дүрт айдан артык эшкә чыкмаганда таләп ителә.

Болар КЗоТның 33 нче маддәсенең 1, 2, 5 пунктларында бәян ителә. Хәзер башка очракларда администрация инициативасы буенча хезмәт килешүен (контрактны) өзү өчен тиешле сайлаулы профсоюз органының ризалыгы таләп ителми.

49 нчы маддәнең дә беренче кисәге яңача бәян ителгән. Йөкле һәм 14 яшькәчә (бала инвалид булса 16 яшькәчә) баласы, шул исәптән аның попечениесендәге баласы булган хатын-кызларга медицина бәяләмәсе (заключение) булганда үз үтенечләре нигезендә администрация тулы булмаган эш көне яки тулы булмаган эш атнасы билгеләргә тиеш.

Элек ял көннәрендә эшләү, башка көнне ял бирү яисә икеләтә күләмдә түләү белән компенсацияләнә иде. Яңа редакциядә 64 маддәдә акчалата компенсация хакында «кимендә икеләтә күләмдә» дип язылган. Бу төзәтмә администрациягә ял көнендә эшләүнең сәбәпләренә, характерына һәм шартларына карап түләргә мөмкинлек тудыра.

Шуңа да игътибар итү кирәк, хәзер ял һәм бәйрәм көннәре бергә туры килгәндә ял көне бәйрәмнән соңгы беренче көнгә күчерелә. Бу хакта КЗоТның 65 нче маддәсендә язылган.

67 нче маддәнең беренче кисәгендә еллык түләүле ялның минималь озынлыгы, алты эш көнле атнадан чыгып исәпләп, 24 эш көне күләмендә билгеләнүе бәян ителә. Шулай ук әгәр коллектив договор яки башка җирле норматив актлар нигезендә каралган очракта еллык өстәмә ял бирү рөхсәт ителә. КЗоТның 68 маддәсенең 5 нче пункты нигезендә законлаштырылган бу.

Кодекстан хезмәт хакын дәүләт нормалавын күздә тоткан 79 нчы маддә төшереп калдырылган. Бу хәзер тулысынча предприятие хокукы. Хезмәткә түләү төре, системасы, тариф ставкалары, окладлар, премияләр, башка төр кызыксындыру түләүләре күләмен, шулай ук предприятие, учреждение, оешма персоналының аерым категорияләре арасында күләм чагыштырмасы мөстәкыйль билгеләнә һәм коллектив договорларда, башка җирле норматив актларда чагылдырыла. Бу 80 нче маддәдә теркәлгән.

Кодекска 85(1) маддәсе өстәлгән. Анда эшне нормадан тайпылып башкарганда (төрле квалификациягә кагылышлы хезмәт үтәгәндә, профессияләрне кушып алып баргында, эштән соң; тәнлә, бәйрәм көннәрендә һәм башка очракларда) предприятиеләр, оешмалар работникларга тиешле өстәмә түләүләр үтк бурычлылар. Түләү ләме һәм шартлары приятие тарафыннан тскыйль билгеләнә коллектив килешү (хезмәткә түләү ту дагы положениед) ла.

КЗоТның 121(3) дәсе дә яңача бәя гән. Хәзер предприя яисә учреждениегә релгән зыян—урлау, тешмәүчәнлек, белә т юк иткән яисә бозган териаль кыйммәтләр китерелгән зыян шул дә бу урында хәрәкәт бәяләрдән чыгып бил ләнә.

Хезмәт дисциплина бозган өчен дисципли җәза билгеләүче 135 маддәгә дә үзгәреш телгән. 3 айга кадәр рак түләүле эшкә күч турындагы 4 нче пу төшереп калдырыл Дисциплинар җәза би нең тәртибендә беркад үзгәреш бар. Хәзер м дый төр җәза биргәнч работниктан язма аңл ма таләп ителергә тие Җәза гаеп эшләгәннән с 6 ай, ә ревизия яки ф нанс-хуҗалык эшчәнлег тикшерү нәтиҗәләре б енча гаеп эшләгәннән с ике ел узгач булса җәз кулланыла алмый. Уго ловный эш алып бару в кыты билгеләнгән б срокка керми. Дисципли нар җәза бирү турынд мотивы күрсәтелгән при каз (боерык) яки карар җәза бирелүчегә имзасы куйдырып таныштырыла

Ә. ГЫЙЛЬМАНОВ,
район прокуроры хезмәтләрен башкаручы, 1 классы юрист.

Үтенечләргә игътибар артсын

Район Советы президиумының чираттагы утырышында халык депутатларының район Советының XII сессиясен чакыру турындагы мәсьәлә каралды. Аны декабрьнең икенче яртысында чакырырга һәм депутатлар каравына халык депутатларының җирле Советларының дәүләт идарәсе органнарында гражданнарның хатларын карау һәм кабул итүләрне оештыру буенча бүгенге шартлардагы эше һәм бурычлары турындагы мәсьәләләрне куярга тәкъдим итү турында карар кабул ителде.

Утырышта шулай ук 9 айда район Советына халыктан кергән язма һәм телдән үтенечләр турында информация дә тыңланды. Анда шул чорда 40ка якын мөрәҗәгать керүе, моның 1991 елның шул чорындагыдан 54кә ким булуы билгеләп узылды. Күп мөрәҗәгатьләр торак, коммуналь һәм юл хуҗалыгы эшчәнлегенә бәйле булуы белән характерлы. Президиумга адресланган хатлар арасында квартирага телефон куйдыруны сораганнары да бар. Өчесе ягулык һәм төзелеш материалы бүлүгә кагыла. Җир реформасы турындагы законны гамәлгә ашыру, хезмәт бәхәсләренә бәйлеләре дә керә. Халык депутатларының район Советына хатлар, үтенечләр һәм шикаятьләр белән мөрәҗәгать итүчеләр арасында Норлат шәһәре, Урта Камылы, Якушкино, Киекле, Фома, Мамык, Сәләнгеш, Иске Чаллы, Кормыш, Яңа Тумба авыл Советлары гражданнары да бар.

Район Советы рәисендә кабул итүдә булучыларның үтенече уңайлыклары булган торак бүлүгә бәйле.

Президиум тикшерелгән мәсьәләләр буенча тиешле карарлар кабул итте.

Т. АЛЕКСЕЕВА.

Басу юлы, игеннәр шавы, алтын гәрәбәләрнең көшелгә күңелле коелуы —һәммәсе үзенчә якын, үзенчә кадерле аларга. Көн һәм төн чиген югалткан, ял һәм эш икенчесе хисабына аерата мөһим әчтәлек алган уракны ел буе физик кына түгел, рухи әзерлектә дә каршы алу аларның гадәтенә кергән. Евгений Васильевич Нефедов, Виктор Васильевич Аввакумов инде дистә елдан артык игмәк язмышы дигәндә фидакарьлекнең югары үрнәкләрен күрсәтеп хезмәт куялар. «Мамык» совхозында моны шулай тиеш дип кабул итәләр, чөнки игенчеләрнең һәр икесе нинди эшкә алынсалар да аны бирелеп, бар күңелләре белән башкара беләләр. Кышын алар гадәттә тракторга күчеп утыралар, терлек азыгы, төзелеш кирәк-яраклары ташу һәм башка хуҗалыкның бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләрен башкаралар.

РӘСЕМДӘ: «Мамык» совхозы механизаторлары Е. В. Нефедов һәм В.В. Аввакумов.

Җирләр сый ала

«Заря» колхозында басуларга ашлама чыгару буенча махсус звено эшли. Узган елның көзендә оештырылды ул. Николай Фролов К-700 тракторында төягеч белән черемәне транспортларга төйи, ә Т-150 тракторында Александр Гражанов, МТЗ-80 тракторында Константин Романов, Николай Морозов, Василий Сенькин, Николай Кашаев, КамАЗ машинасы шоферы Юрий Матвеев һәр көнне басуга 5—6 рейс ясыйлар. Башка эшләрдән бушаган техника да черемә түгүдә катнаша. Ел башыннан бирле колхозда 14500 тонна ашлама кырларга чыгарылды.

Ф. ХӨСӘЕНОВ.

Бәйрәм иттек бергәләп

7 ноябрь көнне авыл клубы шат авазлардан, уен-көлкедән гөрләп торды. Иске Чаллыда, элеккеге еллардагыча авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре бәйрәмен бөтен авыл белән бергә билгеләп үттеләр. Бәйрәмчә бизәлгән залда утыруы үзе бер ләззәт бирә. Йөзебез ак, ә эшебез хак, дигәндәй уңышларыбыз күз алдында. Механизаторлар, терлекчеләр, төзүчеләр, чөгендерчеләр, белгечләр һәм төрле эшләрне башкаручылар, юлда киртәләр күп булса да, авыл хуҗалыгы елын уңышлы тогәлләделәр. Быел җир хуҗаларын ашлык һәм терлек азыгы белән сөендерде: һава торышы азык запасын мул итеп тупларга мөмкинлек бирде, сөт чишмәләре дә әлегә саекмады, ит җитештерү, йон кыркып алу да әйбәт кенә булды. Димәк, сөенерлек урын бар. Шунысы да сөенечле, хуҗалык администрациясе авыл хезмәтчәннәренә мораль яктан гына түгел, матди яктан да булышырга мөмкинлек тапты. Хәер, бүләк алумы, әллә адресына җылы сүзләр ишетү яхшыракмы? Моны тәгаен генә әйтеп бирүе дә читен. Бу көнне барысын да котладылар. Комбайнчылар, тракторчылар, шоферлар артыннан сәхнәгә сыер савучылар, терлекчеләр, дуңгыз, сарык, ат караучылар, кочегарлар менде. Кыскасы, бу көнне беркем дә игътибарсыз калмады.

В. Д. Шувалов, А. Никифоров, В. Я. Нилов кебек ветераннар янында аларның уллары, гаилә традициясен дәвам иттерүчеләр, авыл хезмәте династиясе вәкилләре булуы сөендерә.

Ышанычны аклаганнары өчен зал яшь механизаторларны кайнар кол ладды.

Синдряковлыларга бәйрәмгә район потребительләр җәмгыяте, хуҗалыкның шефлары вәкилләре килгәннәр иде. Райпо идарәсе рәисе М. С. Моратов өлкән сыер савучылар Е. Захарова, З. Микушкина, колхозның иң яхшы терлекчесе В. Макаровка кыйммәтле бүләкләр—чәй сервизы тапшырды.

Юк, шефларның тагын бүләкләре бар иде әле. Алар өч келәм алып килгәннәр иде. Аны уйнату нәтиҗәләре буенча бәхетлеләр өлкән механизатор В. Я. Нилов, яшь тракторчы С. Г. Крот, слесарь А. Лаврентьев булдылар.

Бүләкләр тапшыру бию, җыр, җирле һәвәскәр артистларның шаян сүзләре белән аралаштырып алып барылды. Ләкин иң күңелле мизгел бар колхозчыларның дәррәү кубып авыл культура йортының икенче катына күтәрелеп мул ризыклы өстәлләр артына утыргач булды. Әйе, өстәлләр нигъмәтләргә бик бай иде. Кем әйтмешли, анда кош сөте генә юк иде. Хәер, бу сүз бик дөрес булмас та. Чөнки синдряковлылар өстәлендә «Птичьего молоко» конфетлары да бар иде. Аларга Новороссийскидан виноград шәрабе, Самарадан якташыбыз—икмәк комбинаты директоры бик әйбәт тортлар җибәргәннәр иде. Шуннан соң элемтәләребез юк диген инде?- Халык үзара элемтәләрне өзәме соң!

Бәйрәмнән һәркем — олылар да, яшьләр дә канәгать калды.

Н. ХРАМОВА.

Бу рәсемдә сез Зәйнәп Кыямовна Мифтахетдинованы күрәсез. Ул ит комбинатының сую цехында инде 25 елдан артык эшли. Пенсиядә булуына карамастан, эшен яшьләрчә җитез башкара. Үзе һәрчак ачык йөзле, кешеләрнең үтенечен кире какмас өчен барысын да эшләргә омтыла. Тыйнак, ягымлы, иптәшләренә ярдәмгә килергә әзер торучы Зәйнәп Кыямовнаны биредә барысы да хөрмәт итә.

—Һәртөрле мактауга лаек ул,—диделәр аның турында комбинат җитәкчеләре дә.

Н. Азизов фотосы.

Фаҗигале хәлләрне булдырмыйк

Хуҗалыкларда иң хәвеф-хәтәрле һәм, шунлыктан, иң җаваплы чор—терлекләрне кышлату чоры башланды. Күп кенә хуҗалыклар ут-күздән, электр фаҗигаләреннән кисәтү һәм саклану чараларын тулысынча үтәдек, дип ышанычлы итеп әйтә алмыйлар әле. Ә бит менә кышлату чорында хуҗалыкларга ут-күз иң зур зыянны китерә дә. Күпчелек терлекчелек биналарында электр линияләре бик иске, аларны күптән алыштырырга вакыт. Шулай булуга да карамастан, кайбер участокларда хәтта алар җәй айларында да күздән үткәрелмәгән. Барлык терлекчелек фермаларында да берничәшәр су җылыткыч, пар мичләре, коры кайнар һава куу мичләре, аерым азык эшкәртү цехлары эшли, аларның һәрберсе, игътибарсызлык һәм җавапсызлык яшәгәндә, потенциаль янгын чыганаклары булырга мөмкин.

Шуның өстенә, терлекчелек фермаларының байтагысында, хәвефле хәлләр булган очракта, беркайдан да ярдәм көтәргә мөмкинлек юк, чөнки анда булган телефоннар эшләми, яисә бөтенләй телефонлаштырылмаган. Хуҗалык җитәкчеләре, терлекчелек фермалары мөдирләре күпме генә тырышсалар да, нервларын какшатсалар да район элемтә, электрлаштыру һәм башка хезмәт күрсәтү оешмаларыннан ышанычлы рәвештә кышка керү өчен тиешле ярдәмне, булышлыкны алып җиткермәделәр.

Бу хәлләр безнең Ульянов исемендәге колхоз өчен дә күп еллык чир булып тора. Башка төрле уңайсызлыклар һәм күңелсезлекләрдән тыш та, ут-күздән генә дә ел саен диярлек меңләгән, хәтта миллионлаган сумлык зыян күрәбез. Әле 2 ел арасында гына сыерлар фермасының бер корпусы янып киткән иде, инде быел җәй 50—60 метр озынлыктагы техника, запчастьләр, җиһазлар, узеллар һәм башкалар склады янды һәм миллионлаган сумлык байлык юкка чыкты. Ә бит ут чыккан очракта да зыянны күпкә киметергә, янгынны сүндереп өлгерергә дә мөмкин булыр иде, әгәр производство участокларында телефоннар булса һәм алар төзек булып вакытында хәбәр ителсә, әлбәттә. Бездә, гадәттә, ярдәм янгын бетәр алдыннан гына яисә бернәрсәне дә коткара алмаслык хәлгә әйләнгәч кенә килеп җитә, чөнки вакытында хәбәр итәргә мөмкинлек юк.

Менә Үрнәк бригадасында (авылында) дуңгызчылык фермасы эшли. Анда йөзләрчә баш дуңгыз үстерелә, аларны тәрбияләү өчен 3 җирдә азык эшкәртү, су кайнату мичләре эшли. Шуларны тәэмин итү, нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен ферма мөдиренә тракторга утырып яисә ат белән (бу пычракта!) 5 километрга якын Киеклегә колхоз идарәсенә барырга (кайсы көннәрне икешәр тапкыр) туры килә, чөнки элемтәгә керү өчен телефон эшләми (менә 5 айлык юбилее да якынлашты инде). Хәтта колхозның техника склады янып киткәч тә элемтәчеләр телефонның никадәр әһәмияткә ия булуын аңламадылар, аһзарларга колак салмадылар, аңарга коммерция күзлегеннән генә карап, хак алу өчен генә, дип уй йөрттеләр. Өстәп әйтергә кирәк, авыл эчендә нинди генә хәл, үлем китем, авыру, ут-күз, башка төрле кичектергесез йомыш һәм сәбәпләр булмасын, фермадагы телефон бердәнбер элемтә чарасы иде.

Югарыда әйтелгән һәм әйтелми калган гасабилыклар шундый фикергә китерәләр: әле соң түгел фермаларда һәм башка производство участокларында ут-күз һәм электр куркынычын кисәтү мәсьәләләре һәм чаралары буенча район Советында яисә администрация җитәкчесе каршында конкрет, катгый һәм нәтиҗәле сөйләшү кирәк. Соңга калмыйсы һәм фаҗигале хәлләрне булдырмыйсы иде.

Ә. САФИУЛЛИН.
Үрнәк авылы.

●Менә сиңа мә!

Бәлки ачыклык кертерләр?

27 октябрь көнне иртәнге сәгать 10нар тирәсендә кызыма телеграмма җибәрү өчен элемтә бүлекчәсенә кердем. Һәм ни дисезме—монда миңа котлау телеграммасы тапшырдылар. Датасына карадым да исем китте: бу котлауны миңа күрше Ульяновск өлкәсеннән 23 октябрьдә җибәргән булганнар. Димәк, ул миңа 4 тәүлеккә якын килгән булып чыга, бәгырькәем! Әле нәкъ шушы көнне почтага килмәгән булсам, тагын күпме яткан булыр иде икән! Телеграммаларның Сәләнгеш почта бүлекчәсендәге мондый маҗаралары сирәк хәл түгел. Җитмәсә әле бланкта телеграмманың кабул ителү вакыты турында мөһер дә юк. Район элемтә бүлеге начальнигы бу мәсьәләгә ачыклык кертер һәм җавап бирер дип ышанып калам. Телеграммаларның шулай озак йөрүе гафу ителерлек хәл түгел, ләбаса.

И. МАРИНИН.

РЕДАКЦИЯДӘН: Без дә район элемтә узелы администрациясенең җавап бирүен күптәннән көтәбез. Сезнең сорауга гына түгел, Мамыкта яшәүче пенсионер С. М. Яллинның быелгы елның 14 июнендә район элемтә узелына юлланган хатында, Кәкре Атаудан II группа инвалид Д. Шакиров (26 июнь), «Игенче» колхозы колхозчылары, Норлаттан сугыш һәм хезмәт ветераны А. И. Тимашин (26 август) һәм башка кайбер авторларыбызның хатларында куелган сорауларга да җавап ишетәсебез килә безнең. Бүгенге искәртү әлеге җавапларны тизләтер дип өметләнәбез.

Билгеле булганча, кешеләрнең күңеленең күтәренкелеге өйдәге тәртиптән тора, бигрәк тә авыл хезмәткәрләре өчен өйдә мәшәкатьләр күп. Мотыйгулла Шәйхуллович Шәйдуллин үз авылында зур хөрмәт иясе, чөнки ул күп еллар буе колхозда механизатор булып эшләгән. Соңгы елларда олы яшендә булуына карамастан ул «Чирмешән» колхозында газовик булып эшли. Аның вазифасына авыл халкын газ белән тәэмин итү белән бергә аларны ремонтлау һәм газ плиталәре кую да керә. Һәм аңа кем генә мөрәҗәгать итсә дә ул һәрвакыт ачык йөз белән кешеләргә ярдәм кулы суза. Авыл җирендә шушындый кешеләр эшләгәндә газга мохтаҗлык булмас һәм кешеләрнең күңелләре һәрвакыт күтәренке булыр.

РӘСЕМДӘ: «Чирмешән» колхозы газовигы Мотыйгулла Шәйхуллович Шәйдуллин.

Н. Азизов фотосы.

Кара диңгез буенда

Кара диңгез ярында, Ялта янындагы Мисхор шәһәрчегендә, менә инде берничә ел буена мәһабәт курорт биналары төзелә. Анда 540 урынлы кунак йорты, зур ашханә, ике бассейн, концерт залы бар. Шулай ук хезмәт күрсәтү персоналы өчен берничә йорт салына.

Кырымдагы яңа ял итү комплексына «Ялита» исеме бирелде. Ул нефтехимиклар өчен төзелә, төзелештә 30 дан артык акционерлык оешмасы катнаша. Иң зур пайчылар —Тольятти шәһәрендәге «Синтезкаучук» һәм Татарстанның Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәләре. Аларның беренчесенә 96, икенчесенә 93 даими урын бирелде.

Төзелешне Хорватиядән килгән фирма алып бара. Безнең хәбәрчебезгә Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе дирекциясендә әйтүләренә караганда, кунакханә комплексы биналары һәм эшләүче персонал өчен билгеләнгән дүрт йорт салынып беткән инде. Хәзер биредә соңгы эшләр бара. «Ялита» быел декабрь аенда сафка басарга тиеш.

Татарстан яңалыклар агентлыгы (ТАН).

КИЧ УТЫРГАНДА

БҮГЕН БЕЗДӘ — ЮБИЛЕЙЛАР КИЧӘСЕ

Рәсемдә: Р. Г. Нуретдинова.

Һәммәбездән олы ул, Өебезнең нуры ул...

Тыныч, сабыр адымнар белән редакция ишеген иң әүвәл ул ачып керә. Бүлмәләр бушап, газеталарга кул куелып, типография басучылары әзер полосаларны басарга кәйләгәндә иң соңгы кеше булып ул эштән китә. Көне буе аны әле редакциядә корреспондентлар арасында, әле газетаны җыючы линотипистлар, версткалаучы, кулдан хәреф җыю осталары янында күрәсең. Әле ул чираттагы санга клишелар сайлый, газетаның «чире» булган «тишек»ләр тутыра: яза, тәрҗемә итә. Аннан аның фантазиясе, эзләнүләре нәтиҗәсендә «Дуслык»ның чираттагы санының чираттагы бите туа: менә бире дә полосаны төп материал ачып җибәрәчәк, ә нан менә бу фотоинформацияне куярга кирәк булыр. Аннары — көн яңлыклары, вак и формацияләр китәр. Хәер, һәр санны санап бетерү мөмкинме соң? Бигрәк тә сүз «Дуслык» газетасы редакциясенең җаваплы секретаре Разия Галиулловна Нуретдинова макетлаган саннарны. 40 елга якын гомерен матбугат эшенә багышлаган, корректор, тәрҗемәче, бүлек мөдире һәм җаваплы секретарь булып эшләгән Разия Галиулловна кулыннан күпме кеше күңеленә үтәрлек язмалар, күзләрне, җанны рәхәтләндерерлек отышлы полосалар үткән — аңысын һич санап бетерәм димә.

Разия Галиулловна бүген дә безнең арада. Тыныч, сабыр холкы, һәркемгә аналарча игелекле мөнәсәбәте, редакция хезмәтендәге төрле вакыйгаларны, четерекле ситуацияләрне өлкәннәрчә зирәклек, түземлелек белән кичерә белүе, үзенә хас җайлылык, кабаланмый торган җитезлек белән бөтен коллективны эшкә туплау, юнәлеш бирү сәләте аны редакциябезнең иң мөхтәрәм, иң дәрәҗәле кешесе итә. Нечкә күңелле, гаҗәеп кешелекле Разия апабызга теләсә кемнең сере сыя, авыр чак аның киңәшен һәм ярдәмен тойган кешеләр ал бүген дә чиксез рәхмәтлеләр. Тагын бер гүзәл сыйфаты бар аның: ул искиткеч оста куллы ху... җабикә, кадерле ана, с... екле әби кеше дә. Шуларның һәммәсен тата... хатын-кызларына ха... тыйнаклык, зирәклек һә... эчке горурлык белә... алып бара белгән Разия Галиулловнага шуш... көннәрдә 65 яшь тулд... Хезмәттә, һәртөрле мә... катьләрдә кайнаган Рази... ханым Нуретдинованы... мәгънәле тормышы, яшә... рәвеше, әхлакый сафлы... гы бездә чиксез соклан... горурлану уята. Аны хе... мәттәшләре, күпсанлы га... зета укучылар исеменнә... олы бәйрәме белән кот... лап һәрчак шундый — ... киң холыклы, ачык йөзле, гади дә, зирәк тә булып калуын телибез.

Бар да булды

Тиле яшьлек шаукымына
Иләсләнеп ялгышулар,
Үйламыйча башка килгән
Җиңел-җиңел ялгыш уйлар,
Язмышларга үрсәләнеп
Үкси-үкси яшь коюлар,
Мин-минлекләр чиксез булып
Хисләреңә чик куюлар,

Бер күрергә өмет итеп
Еллар буе сагынулар,
Хыялыңда тик берәүгә
Тәңре итеп табынулар,
Зилзиләдәй бер мизгелдә
Дөрләп китеп кабынулар,
Чарасыздан һушың җуеп
Тигез юлда абынулар,

Хаксызлыктан, саксызлыктан
Кимсетелеп кагылулар,
Гаепсездән рәнҗетелеп
Нахак бәла ягылулар,
Җан өшеткеч тетрәнүдән
Сискәндереп имәнүләр,
«Бар гөнаһым ярлыка!» — дип
Бер ходайга инәлүләр,

Рәхим-шәфкать елмайганда
Елый-елый кинәнүләр,
Хак тәгалә хозурыңың
Берлегенә инанулар —
Газиз баштан бар да үтте.
Тагын ниләр күрәсе бар?
Үзем өчен иң мөһиме —
Шөкер әле, иманым бар!
Иманыма хилаф кылмый
Яшисем бар, яшисем бар...

Газетабызның шигъри күңелле, тынгысыз җанлы, олы йөрәкле даими авторларыннан берсе — Фәүзия Мөхәммәтова бу көннәрдә үзенең 40 яшен билгеләп үтә. Без аңа иҗат уңышлары, сәламәтлек гаиләсенә иминлек һәм киләчәктә дә «Дуслык» белән дуслыгына тугры калуын телибез! Ә газета укучылары бызга Фәүзиянең яңа язмаларын тәкъдим итәбез.

Моң чишмәсе

ҖЫРЧЫ РӘСИМӘ ШАКИРОВАГА

Моң чишмәсе челтер-челтер,
Тавышыңда су агышы...
Гади бер кыз, син — халкымның
Җәүһәрләргә тиң табышы.

Моң чишмәсе, җырлый-җырлый
Күңелләрне ачарсыңмы,
Көйгә-моңга көйгәннәрнең
Сусауларын басарсыңмы?

Моң чишмәсе, сихри серле
Тавышыңда бер тылсым бар,
Җырың аңлап, назлап торган
Бармы икән сиңа тиң пар?!

Моң чишмәсе, тулып-ташып
Саекмыйча тибәрсеңме?
Язмышларга яраклашып
Әллә син дә кибәрсеңме?..

Моң чишмәсе, ургып-ургып
Типсә иде моң агышың,
Югалтмаса иде халкым
Җәүһәрләргә тиң табышын!!!

Өч кызым бар

Тамырлары сугарылып үз канымнан,
Яшәү диган сулыш өреп үз җанымнан,
Үз дәвамым — өч кызым бар үз янымда.
Өч кызым бар.
Күңелемдә
Шыткан гөлнең өч чәчкәсе:
Иң олысы — гөл иленең
Зәңгәр күзле Миләүшәсе,
Уртанчысы — язын аткан
Ап-ак таҗлы Энҗе чәчәк,
Ә кечесе — бар гөлләрнең
Падишаһы — ал Гөлчәчәк!
Иң олысы — көтеп алган иң беренче
куанычым,
Уртанчысы — бар эшемдә ярдәм итәр
таянычым,
Ә кечесе —
Бар кайгымны оныттырып юатырлык
юанычым.

Өч кызым бар — өчесе дә
Сөеп туймас сөенечем,
Кызларымның язмышына
Көенүдән көенечем.
Өч кызым бар — доньялыкта өч
шатлыгым.
Өчесе дә серем сыяр сер сандыгы.
Тәүбә-тәүфыйк, инсаф белән кызларыма
Өметләнәм булырлар дип йөз аклыгы!!!

КОТЛЫЙБЫЗ!

Киекле авылында яшәүче кадерле әтиебез Хатыйп Гариф улы ВӘЛИУЛЛИНга 50 яшь. Без аны туган көне белән кайнар котлыйбыз.

Син булганга бүген без бәхетле,
Синең белән якты көнебез.
Йорт терәге, тормыш яме булып,
Яшик әле тагын йөзне без.

Әнисе, тормыш иптәше, кызлары, кияве, оныклары.

МӨХӘРРИР В. В. ИСХАКОВ.

Учредительләр: редакциянең хезмәт коллективы һәм халык депутатларының Октябрь район Советы.

Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—14, 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм Советлар тормышы бүлеге 2—10—44; рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16; чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; авыл хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51; җаваплы секретарь, хатлар, массалар белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2— 18—67; фотокорреспондент 2—15—63.

Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2.10-54.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Нина ТОЛМАЧЕВА верстка ясады. Наташа ЛУКОЯНОВА басты. Корректор — Зөлфия ВӘЛИЕВА.

Күләме — 1 басма табак.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат.Октябрь типографиясе. Тираж 3751. Заказ 139.